ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.01.2022 г. Заинск № 07

**«Ташламалы транспорт картасы һәм балалар өчен ташламалы транспорт картасы буенча транспорт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле рәвештә транспорт оешмаларына Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 12 ноябрендәге 672 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

"Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына субвенцияләр бирү тәртибен раслау турында» 2020 елның 20 мартындагы 210 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, кадрлар үзгәрүгә бәйле рәвештә, Зәй муниципаль районы уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Ташламалы транспорт картасы һәм балалар өчен ташламалы транспорт картасы буенча транспорт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле рәвештә транспорт оешмаларына Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 12 ноябрендәге 672 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Ташламалы транспорт картасы һәм балалар өчен ташламалы транспорт картасы буенча транспорт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле рәвештә

транспорт оешмаларына Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе 2 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле пункт өстәргә:

2.14 Агымдагы елның декабрь аена субсидияләр белешмәләр-исәпләүләр нигезендә агымдагы елның ноябрь аена тиешле субсидияләр күләмендә күчерелә.

1.2. Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү комиссиясе составын кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында (http://zainsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Г.Х.Никифорова
8(85558)30719

Кушымта
Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
10.01. 2022 ел
07 номерлы карары белән
расланган.

Ташламалы транспорт картасы һәм балалар өчен ташламалы транспорт картасы буенча транспорт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле рәвештә транспорт оешмаларына Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү буенча комиссия составы

| | | |
|---|---|---|
| Хаҗипов Р.М. | - | Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары - комиссия рәисе; |
| Комиссия әгъзалары: | | |
| Архипова А.М. | - | Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш буенча урынбасары |
| Хәбибуллин М.М. | - | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге башлыгы |
| Городнова О.В. | - | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисап бүлеге башлыгы |
| Никифорова Г.Х. | - | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының торак-коммуналь хуҗалык, төзелеш, транспорт, энергетика, элемтә һәм юл хуҗалыгы бүлеге башлыгы |